ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**“ 05 ” февраль 2016 ел** **№ 111**

**2016 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән юл эшләре программасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексынигезендә Арча район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2016 елга муниципаль юл фонды акчасы хисабына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре муниципаль программасын расларга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында басылып чыккан көннән үз көченә керә (http:pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р.В. Хәбибуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
«05» февраль 2016ел, № 111
карары белән расланды

# 2016 ЕЛГА МУНИЦИПАЛЬ ЮЛ ФОНДЫ АКЧАЛАРЫ ХИСАБЫНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ГОМУМИ ФАЙДАЛАНУДАГЫ АВТОМОБИЛЬ ЮЛЛАРЫНДА ЮЛ ЭШЛӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

## ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2016 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларында муниципаль юл фонды акчасы хисабына юл эшләре башкару муниципаль программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | 1.Россия Федерациясе бюджет кодексы.<br>2.Татарстан Республикасы бюджет кодексы.<br>3. "2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында" Татарстан Республикасы Законы<br>2016 елга Арча муниципаль районы бюджеты.<br>5. Арча муниципаль районы башкарма комитетының муниципаль юл фондын төзү турындагы һәм муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен раслау турындагы карары.<br>6. 2016 елга Татарстан Республикасының юл эшләре программасы<br>(2016 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2015 елның 29 декабрендәге 1003 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары)<br>7. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон. |
| Программаның координаторлары | 1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы.<br>2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы<br>3. Татарстан Республикасының юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе. |
| Программаның заказчысы | "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлеге |
| Программаны төп эшләүчеләр | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге. |

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль юл фонды Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179.4 статьясындагы 5 пункты нигезендә формалаша һәм кулланыла.

1.2. Муниципаль юл фонды - торак пунктларның күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларына карата юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү максатларында файдаланылырга тиешле муниципаль берәмлек бюджеты акчаларының бер өлеше.

1.3. Юл фонды акчалары максатчан билгеләнешкә ия һәм юл эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле булмаган ихтыяҗларны тартып алырга яки тотарга тиеш түгел.

## 2. Юл фонды барлыкка килү чыганаклары

2.1. Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турында Арча муниципаль районы карары белән раслана:

1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән расланган бүлүнең дифференциацияләнгән нормативлары нигезендә Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль һәм турыдан-туры куу бензинына, дизель ягулыгына, мотор майларына һәм дизель һәм карбюратор (инжектор) двигательләренә акцизлар Арча муниципаль районы бюджетына күчерелә.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле (муниципаль) әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә, торак пунктларның күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларына капиталь ремонт һәм ремонт ясау өчен субсидияләр рәвешендә бирелә торган керемнәр

3.Юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә физик һәм юридик затлардан, шул исәптән ирекле иганәләрдән, гомуми файдаланудагы җирле (муниципаль) әһәмияттәге автомобиль юлларына карата кире кайтарылмый торган кертемнәр.

Муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме, фактта хисап финанс елында кергән һәм аны төзегәндә фаразланган җирле бюджет керемнәре

күләме арасындагы аерманы исәпкә алып, чираттагы финанс елында үзгәрешләр кертергә тиеш.

2.2. Агымдагы финанс елында файдаланылмаган юл фондының бюджет ассигнованиеләре чираттагы финанс елында юл фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлтелә.

## 3. Юл фонды акчаларын тоту юнәлешләре

3.1. Муниципаль юл фонды акчалары түбәндәгеләргә юнәлдерелә:

1. Җирле (муниципаль) әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын проектлау, төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту;

2. Күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, торак пунктларның күп фатирлы йортларының ишегалды территорияләренә керү юлларын капиталь ремонтлау һәм ремонтлау.

3.2. 2019 елга Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен объект буенча бүлү әлеге программаның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән.

## 4. Юл фонды акчаларын тотуны тикшереп тору

Юл фонды акчаларын тотуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының 9 нчы территориаль бүлеге тикшереп тора.

Инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р. В. Хәбибуллин